ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

*Постановление* *Карар*

2022 елның 30 марты Чистай шәһәре № 223

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 30 июлендәге 425 номерлы
карары белән расланган объектны файдалануга
тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына Чистай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 28 мартындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 425 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.5.1 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (әгәр мондый тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документларында каралган булса)»;

1.2. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.8.2 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) капиталь төзелеш объектының төзелеш өчен рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш»;

1.3. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.8.2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының параметрларына туры килмәү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов